**Балтач муниципаль районы Субаш урта гомуми белем мәктәбенең беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Габитова Сания Ильяс кызының “Яшь хәбәрче” түгәрәге курсыннан эш программасына методик кулланмага рецензия**

Габитова Сания Ильяс кызының “Яшь хәбәрче” түгәрәге курсыннан эш программасына методик кулланма бик кирәкле һәм укытучы тарафыннан бик урынлы эшләнгән. Бу программа һәм методик кулланма балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелгән. Сайланган материал бай, эчтәлекле, эзлекле, программа эчтәлегенә туры килә. Бигрәк тә милли - төбәк компоненты исәпкә алынган. Якташ шагыйрь һәм шагыйрәләр иҗаты аша укучыларны иҗатка тартуы сизелеп тора.

Бүгенге авыр заманда укучыларны матурлыкны күрергә өйрәтү, әдәбиятка, иҗатка тарту бик авыр. Укытучы әлеге авырлыклар алдында туктап калмаган, эшне нәтиҗәле итеп оештырырга алынган.

Программа 5-7 нче сыйныфлар өчен 32 сәгатькә төзелгән.

Программаны дәрестән тыш кулланырга мөмкин.

Профессор кафедры педагогики
и психологии ГАОУ ДПО
«Институт развития образования РТ»,
доктор педагогических наук Г.Х.Ахбарова